КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 3 июль г.Казань № 542

Триатлон буенча ярышлар, Red Bull Air Race авиаузышлар этабын һәм «Мин күкне сайлыйм!» авиация бәйрәмен үткәргәндә су объектларыннан файдалану турында

Россия Федерациясе Су кодексының 6 һәм 25 статьялары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, 23 апрель, 256 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләренең 1.3 нче пункты нигезендә, массакүләм чаралар үткәргәндә кешеләр тормышы иминлеген тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. SVIYAGA SWIM триатлоны буенча ярышлар үткәрү вакытында Свияжск утравы чикләрендәге Зөя елгасы һәм Идел елгасы участогында түбәндәге көннәрдә азсыешлы судноларны, җилкәнле, ял итү, спорт судноларын (гидроциклларны, байдаркаларны, ишкәкле көймәләрне дә кертеп) яр буеннан 600 метр ераклыкта файдалануны тыярга:

2018 елның 6 июлендә 10 сәгать 00 минуттан 19 сәгать 00 минутка кадәр;

2018 елның 7 июлендә 05 сәгать 00 минуттан 17 сәгать 00 минутка кадәр.

2. IRONSTAR&TIMERMAN триатлоны буенча ярышлар, Казан триатлонын һәм «Мин күкне сайлыйм!» авиация бәйрәмен үткәрү вакытында Кремль дамбасыннан «Миллениум» күперенә кадәр Казансу елгасы участогында түбәндәге көннәрдә азсыешлы судноларны, җилкәнле, ял итү, спорт судноларын (гидроциклларны, байдаркаларны, ишкәкле көймәләрен дә кертеп) файдалануны тыярга:

2018 елның 21 июлендә 09 сәгать 00 минуттан 14 сәгать 00 минутка кадәр;

2018 елның 22 июлендә 09 сәгать 00 минуттан 14 сәгать 00 минутка кадәр;

2018 елның 3 августында 09 сәгать 00 минуттан 17 сәгать 00 минутка кадәр;

2018 елның 4 августында 06 сәгать 00 минуттан 13 сәгать 00 минутка кадәр;

2018 елның 5 августында 09 сәгать 00 минуттан 17 сәгать 00 минутка кадәр;

2018 елның 10 августында 15 сәгать 00 минуттан 23 сәгать 00 минутка кадәр.

3. Red Bull Air Race авиаузышлар этабын үткәрү вакытында Киров дамбасыннан Чуйков урамы һәм Гаврилов урамы чатына кадәр Казансу елгасы участогында түбәндәге көннәрдә азсыешлы судноларны, җилкәнле, ял итү, спорт судноларын (гидроциклларны, байдаркаларны, ишкәкле көймәләрен дә кертеп) файдалануны тыярга:

2018 елның 23 августында 12 сәгать 00 минуттан 15 сәгать 00 минутка кадәр;

2018 елның 24 августында 09 сәгать 00 минуттан 20 сәгать 00 минутка кадәр;

2018 елның 25 августында 10 сәгать 00 минуттан 19 сәгать 00 минутка кадәр;

2018 елның 26 августында 10 сәгать 00 минуттан 18 сәгать 30 минутка кадәр.

4. Бу карарның 1 – 3 нче пунктларында күрсәтелгән судноларны файдалануны тыю триатлон буенча ярышлар, «Мин күкне сайлыйм!» авиация бәйрәмен һәм Red Bull Air Race авиаузышлар этабын әзерләү һәм үткәрү өчен җәлеп ителгән судноларга кагылмый дип билгеләргә.

5. Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына:

бу карарның 1 – 3 нче пунктлары белән билгеләнгән тыюны үтәү максатларында, әлеге участокларда көчләрнең һәм чараларның кизү торуын тәэмин итәргә;

халыкка кертелә торган тыю турында (шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша) мәгълүмат бирү эшен оештырырга.

6. Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә, бу карарның 1 – 3 нче пунктлары белән билгеләнгән тыюны үтәү максатларында, әлеге участокларда көчләрнең һәм чараларның кизү торуын тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин